ГЛАВА
КОРНОУХОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОРНОУХОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422644,с. Корноухово,
улица Совхозная, дом 3

422644, Корноухово авылы,
Совхоз урамы, 3йорт

Тел.: (84361) 27205, факс: (84361) 27205, e-mail:Kuh.RS @tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

8 ноябрь, 2021 ел Корноухово ав. № 3

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең **Корноухово, Зюзино, Шетнев-Чирмешән һәм Наумово авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Корноухово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең Корноухово торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 18 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең Корноухово торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 19 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта көн итүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең Корноухово, Зюзино, Шетнев-Чирмешән һәм Наумово авыл торак пунктлары территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан гайре, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга Сез ризамы?

- Корноухово, Зюзино, Шетнев-Чирмешән авылларында урамнарның йөри торган өлешен кышкы чорда карап тоту (урамнарны кардан чистарту);
- Корноухово авылында суга батырыла торган ЭЦВ 6-10-80 маркалы насос сатып алу һәм урнаштыру-1 данә;
- юл-төзелеш материалы сатып алу һәм Корноухово авылының Береговая урамы буенча 400 м озынлыктагы юл кишәрлекләрен ремонтлау;
- юл-төзелеш материалы сатып алу һәм Корноухово авылының Зеленая урамы буенча 300 м озынлыктагы юл кишәрлекләрен ремонтлау;
- Корноухово авылында Совхоз, Эшчеләр бистәсе урамнарында вак таш түшәлгән юл кишәрлекләрендәге чокырларны ремонтлау;
- Корноухово, Шетнев-Чирмешән һәм Зюзино авыллары урам юллары читләрендәге чүп үләннәрне чабу;
- Корноухово, Шетнев-Чирмешән һәм Зюзино авылларында урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, алыштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү;
- Корноухово авылында су челтәрләрен ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү (запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча башкарылган эшләргә, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Корноухово авылында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга куелган стеланы ремонтлау;
- Корноухово авылындагы су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү.

“ЯКЛАП” “КАРШЫ”.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Корноухово авылы, Совхоз урамы, 3 йорт; Шетнев-Чирмешән авылы, Совет урамы, 21 йорт; Зюзино авылы, Үзәк урам, 6А йорт; Наумово авылы, Наумово урамы, 3 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

8. Карар игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Корноухово авыл җирлеге башлыгы А.Р.Гыйлаҗиева

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КОРНОУХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634005160 КОРНОУХОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ